**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

2024 елның 30 маендагы 2244 номерлы карары

# «Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын раслау турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тәкъдиме буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 гыйнварындагы 14 номерлы карарлары нигезендә, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2023 елга муниципаль биремен исәпкә алып карар бирәм:

1. «Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын (кушымта) расларга.
2. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.
3. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның 30 маендагы
2244 номерлы карары карары
белән расланды

## «Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты


«Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проектына түбәндәгеләр керә:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы.

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмә.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары исемлеге хезмәт урынында файдалану өчен документ булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

**I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы**




Условные обозначения:

Границы:

| | |
|---|---|
| | - граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки |
| | - действующие красные линии |
| | - граница земельного участка |
| | - ливневая канализации диаметром 1000 мм |
| | - границы зоны планируемого размещения линейного объекта |
| 1 | - номера характерных точек границ зоны планируемого размещения линейного объекта |
| | - обозначение земельного участка |

Примечание:
Перечень координат характерных точек приведена в приложении к I. Чертежу красных линий и границ зон планируемого размещения линейного объекта

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

### 1. Урнаштыру өчен планлаштырыла торган линия объектының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

«Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Вахитов районында яңгыр канализациясе челтәрен урнаштыруны күздә тота.

Линия объекты территориясен планлаштыру проекты түбәндәгеләргә нигезләнеп эшләнде:

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына;
- Россия Федерациясе Җир кодексына;
- Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планына (2022 елның 22 ноябрендәге редакциядә);
- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (2023 елның 14 декабрендәге редакциядә).

Проектны эшләү өчен беренчел мәгълүматлар проект-смета документларын эшләү өчен техник биремдә бар.

Картографик материал МСК 16 җирлегенең географик координаталар системасында башкарылган.

Проектлау участогында җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектлары урнашкан. Проектлау участогында федераль һәм төбәк әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектлары юк.

«Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты чикләре мәйданы 17059 кв.м тәшкил итә.

«Диаметры 1000 мм булган яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү» линия объектын план буенча урнаштыру зонасының гомуми мәйданы 2462 кв.м тәшкил итә.

### 2. Территорияләрендә линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге җирлекләр, торак пунктлар, шәһәр эчендәге территорияләр исемлеге

Линия объектын урнаштыру зонасы Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә билгеләнә.

### 3. Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектының төп характеристикалары

Порт урамындагы участокта проектлана торган яңгыр канализациясе

челтәре үзагымлы буларак кабул ителде.

Автомобиль юлыннан агып төшә торган яңгыр суларын локаль җыю һәм агынты суларны ябык яңгыр канализация челтәренә чыгару өчен хезмәт итүче яңгыр суларын җыю коелары аша чыгару башкарыла.

Порт урамы буенча проектлана торган яңгыр канализациясе челтәрләреннән яңгыр һәм кар суларын – гамәлдәге яңгыр канализацияләренә, ә Мехчылар урамы буенча Девятаев урамы белән киселештә булган күзәтү камерасына тоташтырып читкә җибәрү каралган.

Нигезнең тимер-бетон плитәләрен коелар урыннарына монтажлау 100 мм калынлыктагы ком өстенә башкарыла. Коеларны, куыш урыннарына ком тутырып һәм кат саен тыгызлап, яңадан күмү каралган.

## 4. Мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге

| № т/б | Объектның кадастр номеры, билгеләнеше, исәп номеры | Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу/ резервлау |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16:50:012302:1 | 15290 | Коммуналь хезмәтләр күрсәтү (код 3.1.1); | Өлешчә мәҗбүри алу |

## 5. Территорияне планлаштыру проектын әзерләгәндә гамәлдәге һәм төзелә торган, саклана торган капиталь төзелеш объектларын (бина, төзелмә, корылма, төзелеш тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзергә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын күрү зарурлыгы турында мәгълүмат

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә капиталь төзелешнең сакланып калган һәм төзелә торган объектлары, шулай ук төзү өчен планлаштырылган объектлар юк.

Кабель салынганчы:

- башка коммуникацияләр белән киселешләр башкарылган;
- кабель корылмаларында проектта каралган терәк конструкцияләр һ.б. монтажланган.

Эшләрне башкару урынында проект документларында күрсәтелмәгән җир асты коммуникацияләре табылганда, эшләр туктатылырга, коммуникацияләрнең кайсы затка каравы билгеләнергә һәм урынга эксплуатацияләүче оешма вәкиле чакырылырга тиеш.

## 6. Линия объекты урнашуга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары, шулай ук проектлау территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектлар юк.

Яңадан ачыкланган тарихи-мәдәни мирас объектлары булганда, проект документларына үзгәрешләр кертеләчәк.

## 7. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 14 пункты нигезендә гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеген эшләү каралмаган.